2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авылы җирлеге Иске Суркино авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

1 декарь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Иске Суркино авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Иске Суркино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү һәм техник күзәтү үткәрү өчен түләү

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Суркино авылы, Үзәк урамы, 77 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Суркино авыл җирлеге башлыгы Н.В. Леонтьев